ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БОЕРГАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАР

17 апрель 2018ел № 4

«Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Боерган авыл җирлегендә
гомуми файдаланудагы урыннарында
беренчел янгын сүндерү чаралары
исемлеген раслау турында»

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында Техник регламент» 22.07.2008 елдагы 123-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, торак пунктларның янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыру максатларында, торак пунктларның янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыру максатларында

КАРАР БИРӘ:

1. Беренчел янгын сүндерү чаралары исемлеге Һәм гомуми файдалану урыннарында урнашкан Янгынга каршы инвентарь исемлеген кушымта нигезендә расларга
2. Боерган авыл җирлегендә беренчел янгын сүндерү чараларын һәм янгынга каршы инвентарьны урнаштыру өчен гомуми файдалану урыннарын билгеләргә.
3. Расланган исемлек нигезендә беренчел янгын сүндерү чаралары һәм янгынга каршы инвентарь булуны тәэмин итәргә.
4. Янгын сүндерү чаралары һәм янгынга каршы инвентарь сатып алу, ремонтлау, саклау һәм эшкә әзерлек өчен җаваплы затларны билгеләргә.
5. Янгын сүндерүнең беренчел чаралары һәм янгынга каршы инвентарьларны бина һәм корылмаларның тышкы ягыннан янгын щитларында урнаштырга.
6. Янгын щитларында янгын сагы чакырулар номерларын күрсәтергә (101, 112 һәм 01);
7. Беренчел янгын сүндерү чараларының үтемлелеген тәэмин итү һәм янгынга каршы инвентарьлар булдыру.

8. Беренчел янгын сүндерү чараларын төзек хәлдә тотарга аларга паспорт мәгълүматлары булдырырга.
9. Тиешле сертификатсыз Янгын сүндерү чараларын куллануга юл куймаска.
10. Беренчел янгын сүндерү чараларын билгеләнмәгән очракларда куллануга юл куймаска
11. Әлеге карарны районның рәсми һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталда бастырып чыгарырга
12. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе З.М.Камилҗанов

«17»апрель 2018 ел
№ 4 нче карарына кушымта

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Боерган авыл җирлеге буенча гомуми кулланылыштагы урыннарында янгын сүндерү беренчел чаралары һәм янгынга каршы инвентарь исемлеге

1. Беренчел янгын сүндерү чараларын урнаштыру өчен Щит*.

2. 10/9 л/массасы булган порошоклы ут сүндергеч, килограмм (апрельдән башлап октябрьгә кадәр))**

3. Металл чиләк - 2 данә.**

4. Лом.**

5. Багор.**

6. Көрәк.**

7. Көрәк.**

8. 0,2 куб. метрлы суны саклау өчен сыйдырышлык (апрель аеннан башлап октябрь)***

Искәрмә:

* Күзәтү һәм якын килү өчен уңайлы урында билгеләнә;

** щит янында урнашкан янгын сүндерү беренчел чаралары;

*** щит янында урнашкан беренчел янгын сүндерү чаралары.